## ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

Инновацион компанияләргә ярдәм булачак

> 2

## УКЫТУЧЫЛАРГА – БҮЛӘК

Мөгаллимнәргә хезмәт хакына өстәмә түләнәчәк

> 2

## ӘГЪЗАМ ГОБӘЙДУЛЛИН:

«Максат – авыл белән шәһәр арасындагы киртәне бетерү»

> 3

## ТӘМЛЕ БУЛСЫН!

Җәмилә Керимова, кеше пешергәнне ашау – ялкаулык түгел, ди

> 4


# ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 187 (28769) | Чәршәмбе | 22 декабрь | 2021 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131


# QRЛЫ, БИТЛЕКЛЕ ГАИЛӘ БӘЙРӘМЕ

## ТАТАРСТАН ЯҢА ЕЛГА ӘЗЕРЛӘНӘ

**Сәламәтлек, бәхет, мәхәббәтнең тыш Яңа ел төнендә кеше тагын нинди теләк тели ала? Хәзерге вазгыятьтә бу, әлбәттә, коронавирус пандемиясенең тизрәк бетүе инде. Татарстанның вице-премьеры Ләйлә Фазлыева да республика халкыннан теләкне белеп теләргә сорады. Яңа ел нинди булыр – билгесез, анысына әзерлек, искесен озату башланды инде. Бәйрәм Татарстан халкына гына түгел, туристлар өчен дә күңелле булачак дип ышандыралар.**

Илдар Мөхәммәтҗанов

Декабрь ахырыннан 9 гыйнварга кадәр мәктәп укучылары өчен 3 меңләп чара оештырылачак

**«Баш тартмадык»**

Яңа ел чараларын республиканың барлык шәһәр-районнары, авыл җирлекләре әзерли. Күңел ачарга мөмкинлек әлеге дә баягы чикләүләр бәрабәренә туды. Татарстан буенча Роспотребнадзор идарәсе җитәкчесе Марина Патяшина әйтүенчә, республикада коронавируска бәйле эпидемиологик хәл тотрыклана. «Дүрт атна дәвамында без авыручылар саны кимүен күзәтәбез, соңгы атнада бу кимү аеруча зур булды һәм 40 процентка җитте», – диде Марина Патяшина. Идарә җитәкчесе сүзләренчә, вазгыятьне тотрыкландыруга күмәк вакцина ясату да йогынты ясаган. Хәзерге вакытка халыкның 74 проценты прививка кадаткан инде. «Бу, һичшиксез, безгә Яңа ел бәйрәмнәрен үткәрүдән баш тартмаска мөмкинлек бирде. Яңа ел тамашаларын үткәрергә рөхсәт итәбез, әмма без куйган таләпләр үтәлергә тиеш», – диде ул.

**Роспотребнадзор нәрсә таләп итә соң?** Әйтик, ресторанда Яңа ел корпоративы уздырырга җыенучыларның QR-кодлары булу мәҗбүри. Бер залда бер генә хезмәт коллективы утыра ала. Яңа ел көненә кадәр кафе-рестораннарга төнге 1гә кадәр эшләргә ярый. 31 декабрьдә исә – иртәнге 3кә кадәр. Җәмәгать тукланыу хезмәткәрләренең барысы да прививкалы булырга тиешлеген инде октябрь аенда чыккан карардан да беләбез. Табын-өстәлләрне бер-берсеннән ярты метр аралыкта урнаштырырга, хезмәткәрләргә битлек һәм пирчаткәдән эшләргә туры киләчәк. «Битлек – коронавирустан саклык чарасы булса, пирчаткә – эчәк инфекцияләреннән», – дип саный Марина Патяшина.

Зурлар бәйрәме ничек узасы аңлашылды кебек. Балалар катнашындагы чараларга килгәндә, кагыйдәләр катгыйрак. 7 яшьтән узган һәр бала бәйрәмдә битлек киярга тиеш. Йөткереп-төчкереп, хәлсезлек кичергәннәргә өйдә калу хәерлерәк булыр.

– Бәйрәмдә баланың йә әтисе, йә әнисе генә катнаша ала. Аның QR-коды булырга тиеш. «Медотвод» яисә прививканың берсен генә кадатуы турындагы белешмә ярамый. Ниндидер чирләре булган кешеләргә, өлкәннәргә андый чараларга бармаска киңәш итәбез, – дип кисәтте Татарстанның вице-премьеры Ләйлә Фазлыева.

Массакүләм чараларга исә аерым таләпләр: театраль тамашалар өчен зал 50 процентка (барлык хезмәткәрләр һәм тамашачылар прививка кадаткан булса – 70) гына тулу, тиешле урыннарда санитайзер булу шарт. Термометрия, дезинфекция турында да онытмау кирәк, билгеле.

Иң яхшысы – гаилә белән. Ләйлә Фазлыева Яңа елны иң якыннар янәшәсендә үткәрүне кулайрак дип саный.

– Республика халкы өчен дә, туристлар өчен дә киңәш шул: күбрәк ачык һавада йөрергә, балалар белән булырга. Бу – гаилә бәйрәме, – диде ул. – Минемчә, 31 декабрь төнендә барыбыз да коронавирус пандемиясенең тизрәк бетүен теләргә тиеш. Күмәкләшеп сорасак, уртак хыял чынга ашар.

Ахыры 2 нче биттә >

## Путин җавап бирә

Коронавируска каршы көрәш, яңа социаль ярдәм чаралары, тышкы сәясәт. Россия Президенты Владимир Путинның еллык матбугат очрашуында шушы һәм башка мәсьәләләр күтәреләчәк. 23 декабрьдә буласы матбугат очрашуы Мәскәү вакыты белән 12.00 сәгатьтә башлана. Чара пандемия башланганнан бирле беренче тапкыр гадәти форматта, ягъни җанлы очрашу рәвешендә үткәрелә. Ил башлыгының журналистлар белән очрашуы федераль телеканалларда, аларның сайтларында һәм YouTube аша күрсәтеләчәк.

## *Бер ел алдан башлыйбыз*

Татарстанда яшәүчеләр өчен социаль әһәмиятле хезмәтләрнең барысы да онлайн форматка күчерелгән. Сүз төбәк, муниципаль дәрәҗәдәге 76 хезмәт турында бара. Исегезгә төшерәбез: Россия Президенты Владимир Путин Хөкүмәткә мондый хезмәтләрне 2022 ел азагына кадәр электрон рәвешкә күчерүне йөкләде.

Республиканың элемтә министры Айрат Хәйруллин әйтүенчә, 2022 ел Татарстанда Цифрлаштыру елы буларак игълан ителгәнлектән, республика халкына бу хезмәтләрдән инде киләсе ел башыннан ук электрон рәвештә файдалану мөмкинлеге тудырылган. Анда Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү, Сәламәтлек саклау, Мәгариф һәм фән, Транспорт һәм юл хуҗалыгы, Урман хуҗалыгы министрлыкларының һәм башка ведомстволар күрсәткән хезмәтләр кертелгән. Хәзерге вакытта бигрәк тә кешене социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану, аз керемле гаиләдәге балага пособие билгеләү, торакка һәм коммуналь хезмәтләргә түләүгә субсидияләр бирү, күпбалалы гаилә статусын билгеләү, җир кишәрлеге планын бирү кебек электрон хезмәтләргә ихтыяҗ зур.

## Техник карау бетә

Дәүләт Думасы мәҗбүри техник карауны бетерү турында закон проектын икенче укылышта кабул иткән. Документта, җиңел машиналар һәм мототранспорт чараларына ия булып, алардан шәхси максатта файдаланучыларның бу мәшәкатьтән азат ителүе күздә тотылган. Ә менә автобуслар һәм йөк машиналарына «техосмотр» узу мәҗбүри булып кала. Бу пассажирлар иминлеген тәэмин итү өчен кирәк.

Шул ук вакытта җиңел машина хуҗалары да үз теләге белән техник карау уздыра ала. Дәүләт Думасы Рәисе Вячеслав Володин әйтүенчә, бу карар чама белән 50 миллион кешенең тормышын җиңеләйтәчәк.

**Вакыйга**

# Рәхмәт кенә ишетерлек булсын

**Биектау халкы Яңа елны шатлыклы вакыйга белән каршылый. Кичә районның тимер юл станциясе бистәсендә яшәүчеләр өчен өч катлы яңа сырхауханә ачылды. Ул «Сәламәтлек саклау» илкүләм проектының «Сәламәтлек саклау тармагында беренчел звеноны модернизацияләү» программасы буенча төзелгән.**

tatarstan.ru

Биектау халкының шатлыгын уртаклашырга килгән Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин сүзләре белән әйтсәк, күптән көтелгән вакыйга бу. Районның бу өлешендә яшәүчеләр соңгы елларда шушы теләкне еш җиткерә торган булган. «Бердәм Россия» партиясе депутатлары белән очрашулар вакытында да яңа хастаханә сораган алар. «Биектаулылар, Казан белән янәшә яшибез, ә үзебездә аппаратура да җитми, урын да аз, дип күптән сорый иде. Федераль программа нигезендә, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов ярдәме белән бинаны ачып җибәрәбез», – диде ачылыш тантанасында парламент башлыгы.

Дөрес, монда моңа кадәр дә сырхауханә булган. Ләкин ул ике катлы кечкенә генә бинада урнашкан. Биредә 30 елга якын хезмәт куйган Люция Җиһаншина элеккеге бинадагы бүлмәләрне бик кысан иде дип искә ала. «Яңа хастаханә якты, матур. Аны күптән көттек. Элеккеге бинада бик кысан иде. Хәзер биредә яңа КТ, УЗИ аппаратлары бар. Хатын-кызларны кабул итү, процедура, манипуляция бүлмәләре аерым. Элек мондый мөмкинлекләр юк иде. Булачак әниләр дә бик шат булыр дип уйлыйбыз», – дип сөйләде Биектау хастаханәсенең бала тудыру бүлеге җитәкчесе «ВТ» хәбәрчесенә.

Ахыры 2 нче биттә >

**Сүзгә-сүз**

**Вячеслав ВОЛОДИН, Россия Дәүләт Думасы Рәисе:**

Коронавирус әле беркая да китмәде. Пандемия шартларында яшәүне дәвам итү турында уйларга кирәк. 2022 елда бөтен дөнья һәм безнең ил алдында торган төп бурыч булып шул кала. Шулай ук безгә фәкыйрьлекне дә бетерергә кирәк. Безнең бурыч – дәүләт башлыгы кабул иткән карарларны закон белән беркетү. Бездә тышкы сәясәт шактый нәтиҗәле. СССР чорында ук шундый булса, күп кенә проблемалар булмый да калыр иде.

## РОССИЯДӘ – ЯҢА ЕЛ САЛАТЫ



**ТАСС белгечләре майонез, йомырка, колбаса, бәрәңге, кыяр, борчак һәм кишер салып әзерләгәндә, Яңа ел табынында төп ризыкларның берсе саналган «Оливье» салатының кайсы төбәктә ничә сумга чыкканын ачыклаган. Татарстанда моның өчен 416,9 сум кирәк.**

*Сумнарда*

| ИҢ КЫЙММӘТ БӘЯ | | ИҢ ОЧСЫЗ БӘЯ | |
|---|---|---|---|
| Чукотка АО | 988,2 | Чуашстан Республикасы | 396,7 |
| Камчатка крае | 784,7 | Волгоград өлкәсе | 396,1 |
| Магадан өлкәсе | 781,2 | Мордовия Республикасы | 383,6 |
| Сахалин өлкәсе | 635,3 | Липецк өлкәсе | 381,2 |
| Мәскәү | 608,8 | Белгород өлкәсе | 377,3 |

## *Күчемсез милек сатып алучылар күбәйгән*

Быел республикада торак һәм җир кишәрлекләрен сату-алу килешүләре күпкә арткан. Росреестрның Татарстан буенча идарәсе 2020 елның 11 аенда торак сату-сатып алу буенча 100 меңләп килешүне теркәсә, агымдагы елда инде бу сан 150 меңгә тулып килә. Җир кишәрлекләренә килгәндә, узган елда – 55 меңнән артыграк, быел 115 меңгә якын кишәрлек сатып алу документлары рәсмиләштерелгән. Шул рәвешле күчемсез милекнең бу төрләренә ихтыяҗ узган елдагы белән чагыштырганда 52 һәм 108 процентка арткан.

Росреестр идарәсе быел 11 ай эчендә барлыгы 1 миллион 215 мең теркәү гамәлен башкарган. Бу – узган елдагыга караганда 37 процентка күбрәк.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

**Дөньяда**

## ТӨРЕКЧӘ ВАЛЮТА АЛЫШТЫРУ

Бөтен дөньяда глобаль инфляция үз адымнарын кызулата. Атна башында Англиядән бер тәүлек эчендә электр энергиясенә күпләп сату бәясенең 35 процентка сикерүе турында хәбәр килеп иреште. Икътисад белгечләре мондый сикерешне сюрреализм дип бәяләп өлгерде инде. Англиядә кәгазь акчага алтын сатып алуны тыйдылар дигән әлегә рәсми расланмаган хәбәр дә бар газета хәбәрчесенең «Телеграм»ында. Европаның башка илләрендә дә энергия чыганакларына бәяләр марафоны дәвам итә. Газга фьючерс бәяләре рекордлар куя, мәсәлән. Валюталар сугышы кискенләшкән төбәкләр бар.

Милли валюта курсының мәтәлчек атуы буенча алгы планга төрек икътисады чыкты. Бер нәрсәне истә тотарга кирәк: соңгы ике елда Төркия дөнья күләмендә икътисады иң тиз үсүче илләрнең берсе булды. Сәнәгать товарлары экспортын нык үстереп, Әнкара технологик яктан куәтле державалар сафына басарга омтыла. Вәләкин экспорт кына түгел, импорт та нык үсә шул. Дөрес, төрекләр халык куллануы товарлары түгел, технологик җиһазлар сатып ала. Бу аларның үсеше өчен зур әһәмияткә ия. Тик импортның экспортны узып китүе милли валютага нык суга. Җитмәсә, илнең тышкы әҗәтләре дә гадәттән тыш зурайган. Эчке инфляция дә рекордлар куя. Менә шул факторлар төрек лирасын аударды да инде.

Валютаның зәгыйфьләнүе экспортка булыша, әлбәттә. Әмма курсның кискен мәтәлчек атуы илдәге хәлне кискенләштерде. Ил гражданнары Хөкүмәткә каршы масштаблы протест акцияләре оештырды. Минималь хезмәт хакын күтәрүне таләп иттеләр. Валюта курсының түбәнәюенә, Эрдоган кушуы буенча, Үзәк банкның төп ставканы кечерәйтүе дә этәргеч бирде. Бу хәлләр төрек акцияләренең кыйммәтен югалтуга да китерде. Фонд биржасы бик еш сәүдәне туктатып тора башлады.

Илдә барган ризасызлык фонында хакимиятләр халыкның беренче таләбен өлешчә канәгатьләндерделәр: минималь хезмәт хакын 4250 лирага кадәр күтәрделәр. Доллар иң нык кыйммәтләнгән көннәрдә бу сан 270 долларга тиң иде. Безнең акча белән 20 мең сумга якын. 2017 елда илдә минималь хезмәт хакы 1404 лира булган, АКШ валютасында 400 долларга тәңгәл килгән.

Дүшәмбе көнне Эрдоган яңа икътисади курс – милли валютаны коткару сәясәтен игълан итте. Ел башында бер доллар 8 лира белән бәяләнсә, декабрьнең беренче көннәрендә Америка кәгазе 13 лирага кадәр кыйммәтләнде, ә соңгы көннәрдә хәтта 18 лирага җитте. Төрекләр акчаларының 60 процентын чит ил валюталарында саклый башлады. Эрдоганның яңа икътисад сәясәте милли валюта курсы түбәнәйгәндә байлыгын лирада саклаучыларның югалтуларын каплауга юнәлтелгән. Шулай ук дәүләт облигацияләрен сатып алучыларның керемнәрен салымнан азат итү турында да белдерү бар. Эрдоган вәгъдәсе ил валютасына ышаныч уятты. Лираларны кулда тоту хәвефсез була башлады. Президент чыгышыннан соң өч сәгать эчендә лира бер долларга 18,4тән 14,79га кадәр кыйммәтләнде. Бу юллар язылганда инде бер долларга 13,54 лира бирәләр. Минималь хезмәт хакы 317 долларга кадәр үсте. Безнең акча белән 23 мең сумны узып китте. Ягулык салучылар бензинга бәяне күтәрергә җыенган иде, ниятләрен туктаттылар. Лидерның бер чыгышы төрекләрнең матди хәленә шуның кадәр үзгәреш кертте. Бу уңай үзгәрешләр киләчәктә сакланырмы – анысын бераздан күрербез.

**Россиядә**

## ҮЗЕМ ТАПКАН МАЛ ТҮГЕЛ

Бездә валюта кризисы булганда авырлык халык җилкәсенә төшә. Гаҗәп нык кыйммәтләнгән углеводородлар сатканда да, экспорт импортны күпкә узып китсә дә, бюджет профицитлы булып салым акчасыннан бүселсә дә, валюта курсы мәтәлчек атканда безнең кесәләр зур югалту кичерә.

Бездә бит инфляция дә ике төрле: Росстат бәяләр үсешен үз калькуляторы белән исәпли, «Ромир» – социаль һәм маркетинг тикшеренүләре белән шөгыльләнүче компания – башка калькуляторга сала саннарны. Шуңа күрә Росстатның ноябрь инфляциясе 8 проценттан аз гына югары булса, «Ромир»ныкы 17 проценттан артыграк икән. Икенчесен реаль инфляция дип атау гадәткә кергән. Кара халык исә бәяләр үсешен 30 проценттан арта дип белә.

Бәяләр үсешендә дәүләт сатып алулары дигән схема (госзакупки) бик зур роль уйный. Чиновниклар «үзем тапкан мал түгел, хөкүмәтнеке җәл түгел» дигән принциптан чыгып эш итәләр. Бу бик күптәннән – инде туксанынчы еллардан ук килә торган ямьсез традиция. «Откат» дигән нәрсәне кем генә белми? Менә шул откатлар елдан-ел үсеп, астрономик саннарга җитә.

Югары икътисад мәктәбе белгечләре соңгы көннәрдә генә дәүләт сатып алулары вакытында чиновниклар кесәсенә күпме кыек акча яуганын исәпләп күрсәтте. Алар дәүләт контрактларына тендерларда катнашучы меңнән артык компаниядән сорашып белешкәннәр һәм бәянең 20 проценттан артыграгы откат булуы ачыкланган. Акчага күчергәч, 6 триллион сум килеп чыга икән. Бу сан илнең ике оборона бюджетына, көч структураларының 3 еллык бюджетына, югары белем системасының 6 еллык бюджетына тиң, ди. Чиновниклар кесәсенә эчке тулай продуктның 6,2 проценты төшеп сеңә. Бу мәгълүматны дүшәмбе көнне РБК мәйданга чыгарды. Дөрес, Хисап палатасы ел саен триллионлаган сум акчаның тиешсез урыннарга юкка чыгуы турында кисәтеп килде моңарчы да. Без ул хәлләргә бик күнектек.

Бер яктан караганда, тендер булгач, бюджет акчасын сакларга тиеш инде ул, дәүләт сатып алулары иң түбән бәя тәкъдим иткән компанияләр өчен генә контрактларга юл ачарга тиеш. Тик тормыш чынлыгы башкача килеп чыга. Тендерда кемнең җиңәсе ул оештырылганчы ук мәгълүм була инде. Откатны кем күбрәк түли, тендерны шул ота. Откат суммасы 3 проценттан алып 65 процентка кадәрге аралыкта тирбәлә икән.

Россиядә әлегә коррупцияне туктатып булмый дип саный рәсми даирәләр. Президент сүзчесе Дмитрий Песков әфәнде март аенда гына безнең җәмгыятьнең әле моңа «өлгермәвен» аңлатып, «кешеләр үзләре ришвәт бирәләр» диде һәм якындагы вакытта гына берни дә үзгәрмәс дигән фикер белдерде. Үзгәреш бар ул үзе, әмма кире якка: коррупция тоталь рәвештә үсә.

## ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

**Казанда Президент Рөстәм Миңнеханов рәислегендә Татарстан Инвестиция-венчур фонды Попечительләр советының киңәйтелгән утырышы узды.**

«Бүген безнең уңышлы хезмәттәшлегебез нәтиҗәсендә Татарстан инновацияләр җәлеп итү үзәгенә әверелде. Ел саен Россия венчур форумын, шулай ук «Татарстан өчен 50 иң яхшы инновацион идея» һәм «ИДЕЯ-1000» бәйгеләрен уздырабыз», – диде Президент утырышта катнашучыларга. Ә иң өметле инновацион компанияләр махсус ярдәм күрсәтүне күздә тоткан акселерация программасын үтә. Нәтиҗәдә, пандемиягә карамастан, галимнәр һәм уйлап табучылар тарафыннан кызыксыну арта. «Шуңа күрә әлеге ярдәм чараларын гамәлгә ашыру киләсе елда да дәвам итәчәк», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Утырыш ахырында Татарстан Хөкүмәте һәм «Фәнни-техник өлкәдә предприятиеләрнең кече формаларын үстерүгә ярдәм итү фонды» арасында үзара хезмәттәшлек турында килешү имзаланды. Документка Президент Рөстәм Миңнеханов һәм Фондның генераль директоры Сергей Поляков кул куйды. Килешү фәнни-техник өлкәдә кече эшкуарлыкка ярдәм итүгә һәм Татарстан социаль-икътисади үсешенең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында фәнни-инновацион проектларны гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән.

Утырыштан соң «Татарстан өчен 50 иң яхшы инновацион идея» бәйгесенең җиңүчеләрен котладылар. Быел әлеге бәйгедә катнашу өчен 1953 гариза кабул ителгән. Төрле номинацияләрдә барлыгы 165 җиңүче ачыкланган. Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин әйтүенчә, әлеге бәйге идея һәм талантларны эзләп табарга, ачарга, иң яхшыларын ачыкларга мөмкинлек бирә.

tatarstan.ru

**Татарстанда автомобильләргә газ тутыру буенча яңа 10 компрессор станциясе файдалануга тапшырылды. «Газпром» офисыннан видеоэлемтә режимында узган тантанада Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм «Газпром» идарәсе рәисе Виталий Маркелов катнашты.**

Станцияләр Казанда, Түбән Кама, Әлки, Апас, Яшел Үзән, Лаеш, Менделеевск, Питрәч һәм Тукай районнарында урнашкан.

Рөстәм Миңнеханов, «Газпром»ның Татарстан өчен стратегик партнер булуын билгеләп үтте. Газ-мотор ягулыгы базары – ике арадагы уңышлы хезмәттәшлекнең ачык үрнәкләреннән берсе, диде ул. Президент әйтүенчә, 2013 елда, әлеге базарны үстерү программасы тормышка ашырыла гына башлаганда, Татарстанда нибары 11 газ заправкасы булган, хәзер исә – 38. Ул шулай ук автомобильләргә газ тутыру станцияләренә 2 миллиард сумнан артыграк күләмдә инвестицияләр җәлеп ителүен, мондый ягулык куллануның икътисади яктан да, экологик яктан да файдалы булуын искәртте.

Рөстәм Миңнеханов сүзләренә караганда, автозаправка челтәрен үстерү белән беррәттән, ягулык сыйфатында газ кулланучы техниканың санын арттыру җәһәтеннән дә зур эшләр алып барыла. Газ белән эшләүче техниканың саны, 2013 елдан бирле 12 тапкыр артып, бүген 11 мең берәмлектән артыграк.

## *QRлы, битлекле гаилә бәйрәме*

kzn.ru

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

**Сан**

- Казанда **310**лап кунакханә, ял базасы, хостел һәм шифаханә Яңа ел бәйрәменә килгән туристларны каршы алырга әзерләнә. Аларның **70** проценты тулы инде. **2–5** гыйнвар көннәрендә туристлар ташкыны **80** процентка җитәр дип фаразлана.
- Шартлаткыч, салют һәм башка пиротехниканы файдалану өчен Татарстан буенча **1164** мәйданчык эшләячәк.
- Яңа ел төнендә башкалага **220** меңләп кунак килер дип көтелә. Хокук саклау органнарының **3** меңләп вәкиле тәртип сагында торачак.

**Күреп кенә өлгер**

Теләсә кайсы бәйрәм мәдәният һәм сәнгать өлкәсе кешеләре өчен урак өсте белән бер ул. Татарстанда Яңа ел бәйрәме һәм ял көннәренә йөзләгән чара тәгаенләнгән. Аларны музей, театр, филармония кебек мәдәни оешмалар тәкъдим итә. Барысын да санап китү мөмкин эш түгел. Иң яхшысы – бу учреждениеләрнең афишасын карау.

Татарстанның мәдәният министры Ирада Әюпова республикадагы тамаша залларын 70 процентка гына тутырырга рөхсәт булуын искә төшерде. Декабрь аендагы Яңа ел тамашаларына билетларның 57 проценты сатылып беткән инде. Әйтик, «Әкият» курчак театрында 19 меңләп билетның берничә йөзе генә калган. Гыйнварда буласы тамашаларга билет табарга мөмкин әле. Ил-көндәге вазгыятьне исәпкә алып, кешеләрне күпләп җыймас өчен, көненә дүртәр тамаша күрсәтәләр.

«Тамашаларның күпме урыс, күпмесе татар телләрендә?» – дип кызыксындык министрдан. Төгәл сан әлегә билгеле булмаса да, чараларның якынча 30 проценты татар телендә узачак дип ышандырдылар.

Казан Башкарма комитетының мәдәният идарәсе башлыгы Азат Абзалов ачык һавада 160лап чара оештырылачагын белдерде. Планлаштырылган мәдәни чараларның гомуми күләмен исә санап бетерерлек түгел. Азат Абзалов мэриянең сайтын **(kzn.ru)** карап барырга киңәш итте.

Күңел ачып кына калмыйча, спорт белән шөгыльләнү өчен дә мөмкинлекләр тудырылачак. Казан тирәсендә генә дә 82 хоккей мәйданчыгы, 21 шугалак эшләячәк.

21–27 декабрь аралыгында Казан паркларындагы чыршылар «кабыначак».

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

## Рәхмәт кенә ишетерлек булсын

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Дөрес, элеккеге бина да буш тормаячак. Анда районның балалар хастаханәсе «башка чыгар» дип көтелә. Әлегә ул бүлек район үзәк хастаханәсе белән бер бинада урнашкан. Гомуми мәйданы 2723 квадрат метр булган яңа хастаханә төзелешенә 350 миллион сумга якын акча тотылган. Бирдә эшләүче табиблар 124 торак пунктта яшәүче 52683 кешегә хезмәт күрсәтәчәк. Монда барлыгы 61 табиб һәм 68 шәфкать туташы эшләячәк.

Баш табиб Рамил Зыятдинов сүзләренә караганда, сырхауханә яңа КТ, рентген аппаратлары, маммографлар, УЗИ, стоматология җайланмалары белән җиһазландырылган. «Бу сырхауханә клиника-диагностика үзәге функциясен үтәячәк. Ник дигәндә, бездә беренчел амбулатор ярдәм биш амбулатория, бер участок хастаханәсендә күрсәтелә. Авыруга тагын да җентеклерәк тикшеренү узып, тар белгечләргә күренергә кирәк булса, ул бирегә җибәреләчәк», – дип ачыклык кертте ул.

Биектауда «Земство табибы», «Земство фельдшеры» программалары да уңышлы гына эшләп килә. Программа эшли башлаганнан бирле районга барлыгы 46 (42 табиб һәм 4 фельдшер) белгеч җәлеп ителгән. Якын арада Биектауда тагын 2 ФАП ачылачак. Анда да әлеге программа нигезендә тагын ике фельдшер эшкә кайтыр дип көтелә. Шулай да районда кайбер белгечләргә әле дә булса кытлык саклана икән. Рамил Зыятдинов сүзләренә караганда, бүген Биектауның дәвалау оешмаларына невропатолог, психиатр кирәк.

Кадрлар мәсьәләсенә үз чыгышында Фәрит Мөхәммәтшин да игътибар итте. «Биектау районы табиблар белән 95 процентка тәэмин ителгән. Бүгенге шартларда бу – яхшы күрсәткеч. Без ак халатлы кешеләргә ковид шартларында куркыныч, кыю, җитди эшләре өчен рәхмәтлебез», – диде парламент башлыгы. Сырхауханә белән танышып чыкканнан соң, миллионнарча сум торган яңа җиһазларның кадерсезләнмәвен, анда үз эшен белеп башкарган тәҗрибәле белгечләр генә хезмәт күрсәтүен теләде ул. «Яңа сырхауханәдән район халкы да канәгать булыр дип уйлыйм. Алардан рәхмәт кенә ишетерлек булсын», – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Татарстанның сәламәтлек саклау министры урынбасары Илдар Фатыйхов сүзләренә караганда, «Сәламәтлек саклау тармагында беренчел звеноны модернизацияләү» программасы кысасында Татарстанда барлыгы 49 ФАП ачарга планлаштырыла. Шушы ук программа кысасында тагын өч табиб амбулаториясен дә сафка бастырырга җыеналар. Шул рәвешле якын арада Яшел Үзән, Минзәлә, Әгерҗедә яңа балалар хастаханәләре ачылачак.

Сүз уңаеннан, ачылыш тантанасында Фәрит Мөхәммәтшин табиблардан халыкны прививка кадатырга үгетләүләрен дә сорады. «Татарстанда 2 миллионнан артык кеше вакцина ясаткан. Калганнар исә чир йоктырудан куркып, киеренке халәттә йөри. Сезне, табибларны, тыңласыннар. Әле авырмаган кешеләрне сакларга кирәк, үгетләргә тырышыгыз», – диде парламент башлыгы. Татарстан сәламәтлек саклау министры Марат Садыйков сүзләренә караганда, соңгы арада республикада, дөрестән дә, вакцина ясатучылар саны кимегән. «Өч атна элек көненә 29 мең вакцина ясаган булсак, хәзер бу сан 3–4 мең чамасы тәшкил итә», – ди министр.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

# ДӘРЕСЕҢӘ ТИГӘН ӨЛЕШЕҢ

**Акча-макча**

**Яңа ел алдыннан республика укытучыларын саллы күчтәнәч көтә. Әйтик, Казанда хезмәт хакына өстәмә рәвешендә 50 мең сум акча түләргә җыеналар. Башкала укытучыларына барлыгы 552,3 миллион сум акча каралган. Район-шәһәрләрдә дә педагогларны сөендерәчәкләр. Дөрес, суммалары төрлечә. «ВТ» хәбәрчесе халык теленә «Путин түләүләре» дип кергән өстәмә акчаның күләмен белеште.**

Өстәмә түләнгән акчаны премия дип атау да дөрес түгел. Президентның «Май указы»н үтәү, ягъни укытучыларның хезмәт хакын төбәктәге уртача эш хакы дәрәҗәсенә җиткерү өчен бирелгән сумма бу. Бу күчтәнәч ел ахырына кадәр ияләренә барып җитәргә тиеш. Күңелле яңалыкны күңелсез кабул итүчеләр дә юк түгел. Ник дигәндә, әлеге акча барлык директор һәм урынбасарларга да тәтемәячәк. Бер караганда, алар арасында да укытучылар кебек үк дәрес бирүчеләр бар. Республика мәгариф хезмәткәрләренең профсоюзлар берлеге рәисе Юрий Прохоров әлеге мәсьәләне хәл итү өчен Казан мәгариф идарәсенә хат җибәргән иде. Алары исә бу сорау белән республика Мәгариф һәм фән министрлыгына чыккан.

– «Путин түләүләре»н укытучылар гына алачак. Әмма директор урынбасарларына әләкми дигән сүз түгел. Әгәр кеше урынбасар вазыйфасын да алып бара, әмма аның төп эше укытучы икән, бу очракта өстәмә акча түләнә. Төп эше – урынбасар икән, каралмаган. Түләүләр район буенча билгеләнеп, һәр белем бирү оешмасына җибәрелә. Аны директор хәл итә, – диде Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының матбугат хезмәт җитәкчесе Алсу Мөхәммәтова. – Казан укытучыларына түләнәсе акча 50 мең сумнан артып китә. Әмма бу һәр районда да шундый сумма булачак дигән сүз түгел. Ул укытучының эш күләменә карап билгеләнә.

Быел укытучыларга өстәмә акча түләнгән инде, тик ул суммалар төбәктәге уртача хезмәт хакын куып җитәр өчен җитеп бетмәгән.

– Бер мәртәбә түләүләр башка елларда 3–5 мең сум тирәсе була иде. Ә быел аның күләме зур. Аның артуы хисапка бәйле. Без Путин каршында «Май указы»ның үтәлеше буенча хисап тотарга тиеш, – ди Юрий Прохоров. – Әгәр Казанда түләү 50,9 мең сум булса, районнарда ул күпкә азрак. Бу әлеге оешманың хезмәт хакы фонды күләменә бәйле.

2022 елда мондый зур акча бирелмәскә дә мөмкин. Ни өчен дигәндә, киләсе елдан укытучыларның гына түгел, мәктәп директоры, урынбасар, кече тәрбияче, пешекче, техник хезмәткәрләрнең дә хезмәт хакы артачак. Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин «Инстаграм» сәхифәсендә узган «туры элемтә»дә акчаның уртача 2,5 меңнән 5,5 мең сумга кадәр артачагын әйткән иде. Моннан тыш, стимуллаштыру һәм компенсация түләүләренең күләме дә үзгәрәчәк. Сыйныф җитәкчеләренә бирелә торган акча да саклана.

– Мәктәп директоры, урынбасарларына «декабрь акчасы» әләкми. Бер караганда, бераз үпкә дә бар. Без дә укытабыз бит. Тик моны тышка чыгармыйбыз. Икенче яктан, укытучы берничә башка өстенрәк булырга тиеш. Акчасы күп булса, укытучы эшенә ябышып ятачак. Моңа кадәр аларга бер сүз әйтергә дә курка идек. Ни өчен дигәндә, хезмәт хакы аз, дип укытучылар теләсә кайчан эштән китәргә мөмкин. Авыл җирендә укытучы табу җиңел түгел, – диде исемен әйтергә теләмәгән авыл мәктәбе директор урынбасары.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Кукмара районы мәгариф идарәсе башлыгы Илфат Әхмәдуллин әйтүенчә, хезмәт хакы белән бергә 103 мең сум алучылар да, шул ук вакытта ярты ставкада эшләүчеләргә 20–25 мең сум гына акча тигән очраклар да бар.

– «Май указы» буенча таләпләр үтәлеп бетә дип санамыйм. Ни өчен дигәндә, белем бирү йортларында укытучыларның эш күләме бер төрле генә түгел. Кемдер – бер, кемдер аннан күбрәк яки азрак ставкага эшли. Әгәр укытучы 1,5 ставкада дәрес бирсә, андыйларныкы 50–60 мең сум чыгачак. Авылда кайбер укытучының сәгать саны аз, әмма ул бик сыйфатлы эшләргә мөмкин. Яхшы укытучы булса да, премияне аз алачак. Шундый очраклар белән килешеп булмый. Әлеге акчаның мәктәп директорлары, урынбасарларга каралмавы да – зур кимчелек. Алардан башка мәгариф системасын алып барып булмый. Район бюджетыннан исә моның өчен акча бирә алмыйбыз. Бездә дә премия тигез түгел. Укытучыларга йөкләнеш ничек бирелә, шуңа карап бүленә, – ди Илфат Әхмәдуллин. – Укытучылар Яңа ел күчтәнәчен көтә инде. Бу атнада кулларына эләгер дип уйлыйм. Алар моңа лаек. Мөгаллимнәрне хөрмәт итәргә кирәк. Укытучылар бүген аена 80–100 мең сум акча алырга тиеш дип саныйм.

Мәктәп укытучылары гына түгел, вузларда белем бирүче мөгаллимнәргә дә Яңа ел премияләре киләчәк. КФУ ректоры карары белән укытучыларга 45 мең сум күләмендә матди ярдәм биреләчәк.

Сәрия МИФТАХОВА

## ӘГЪЗАМ ГОБӘЙДУЛЛИН:

# «КЕШЕНЕҢ АВЫЛДАН КИТҮЕ – ТАБИГЫЙ КҮРЕНЕШ»

**Авылда яшәүче бер генә кешенең дә авыл советы башлыкларына йомышы төшмичә калганы юк. Зур, күләмле проблемалардан алып шәхси мәсьәләләргә кадәр ярдәм өмет итеп халык алар янына бара. Шушы көннәрдә узачак муниципаль берәмлекләр Советының XVI съезды алдыннан «Татарстан муниципаль берәмлекләре Советы» Ассоциациясе рәисе Әгъзам ГОБӘЙДУЛЛИН белән җирлек башлыкларының абруе, хезмәт хаклары һәм нәрсә белән янып яшәүләре турында сөйләштек.**

– Муниципаль берәмлекләрнең вәкаләтләре бик зур, – дип сүзен башлады Әгъзам Гобәйдуллин. – Аларның барысы да халыкның тормыш шартларын яхшыртуга корылган. Соңгы елларда республикада бик күп программалар эшли. Аларның максаты – авыл белән шәһәр арасындагы киртәне бетерү. Бу исә – яхшы юллар, матур мәктәпләр, клублар, өй эчендәге шартлар. Бүген мин авыл белән шәһәр тормышы арасында аерма юк дип әйтә алам. Кайсы гына авылга барып керсәк тә, йортларына газы, суы кергән, хәтта ваннасы белән бәдрәфенә кадәр бар. Бу эшләрдә район җитәкчелегенең дә, авыл советы башлыкларының да роле зур.

**:: Пандемия күп нәрсәләргә үзгәреш кертте. Сезнең фикерегезчә, муниципалитетлар елны нинди күрсәткечләр белән тәмамлый? Әлеге ел авыл советы башлыкларын ничек үзгәртте?**

– Чыннан да, барыбызга да күп нәрсәгә җайлашырга туры килде. Шушы тыныч булмаган вазгыятьтә дә эш темпын киметмәскә, планлаштырган эшләрнең барысын да эшләргә кирәк иде. Пандемия, беренче чиратта, бер-беребезгә карата игътибарлы булырга кирәклеген өйрәтте. Җитәкчеләр үз-үзләрен генә түгел, әйләнә-тирәдәгеләрнең дә сәламәтлеген кайгыртырга тиеш булды. Пандемиянең зур авырлыгы беренче чиратта эшмәкәрләргә төште. Кемнәрдер эшен туктатырга, кемдер эштән китәргә мәҗбүр булды. Шушы вакытта да район һәм авыл җирлеге башлыклары аларга ярдәм кулы сузарга тырышты. Алар халык арасында да аңлату эшләре алып барды. Аеруча вакцина белән бәйле мәсьәләдә аларга дөрес мәгълүмат бирергә кирәк иде. Кызганыч, халык тискәре хәбәргә бүген күбрәк ышана. Аның сәбәбен аңлыйбыз да шикелле. Хакимияткә ышаныч җитеп бетми. Димәк, бу мәсьәләдә безгә, җитәкчеләргә, ныклы эш алып барырга, халыкка вәгъдә иткән сүзеңне вакытында үтәргә кирәк.

**:: Әгъзам Саматович, коронавирус белән бәйле вазгыятьтән тыш, бүген авыл җирлекләре башлыкларын нинди төп мәсьәләләр борчый? Аларны бүген нәрсә сөендерә һәм көендерә?**

– Бүген авылда яшәү шартлары яхшы булуга карамастан, кызганычка, халык аннан китә. Яшьләр китә, чөнки эш белән тәэмин итү проблемасы бар. Көтелмәгән реформалар нәтиҗәсе буларак, колхозлар бетте. Алар урынына авылларга зур инвесторлар килеп керде. Элеккеге колхоз системасындагы фермалар юкка чыгарылды һәм кешеләр эшсез калды. Бу процесс әле дә булса дәвам итә. Икенче яктан, безнең авыл хуҗалыгында продукция җитештерү кимеми. Мегафермалар төзелә, техника егәрлеге арта. Шунлыктан кул хезмәтенә ихтыяҗ бетте диярлек. Узган гасырда Россиядә 150 мең авыл юкка чыккан. Ә соңгы 21 ел эчендә 35 мең авыл беткән. 1–2 кешелек кенә 32 мең авыл бар. Димәк, алары да юкка чыгарга хөкем ителгән дигән сүз. Ләкин авыллар бетүдән фаҗига ясарга кирәкми. Бу процессны туктатып булмый. Бәлки булыр иде дә, ләкин моның өчен сәясәтне үзгәртергә, бик күп чыгымнар чыгарырга кирәк. Авылда халыкның 25–26 проценты яши. Шуның 17 проценты – пенсия яшендәге кешеләр. Башка чит илләрдә дә авылда халыкның 1,5–2 проценты гына яши. Шуңа күрә авыллар бетү, кешенең аннан китүе – табигый күренеш. Безгә исә матур яши торган, ныклы, киләчәге булган авылларга күбрәк игътибар күрсәтеп, аларга ярдәм итәргә кирәк. Авылларда зур предприятиеләрнең филиалларын төзү дә яхшы күрсәткечләргә ирешергә мөмкинлек бирер иде. Республикада андый үрнәкләр дә бар. Чынлыкта хәзер ит, сөт продукциясен сатуда берниндидә проблема юк. Тырышкан кешегә уңышка ирешер өчен бөтен мөмкинлекләр бар. Иренмичә эшләргә генә кирәк. Бүген авылларда иң зур проблемаларның тагын берсе – су белән тәэмин итү. Ә моның өчен финанслау җитәрлек булу кирәк. Шушы көннәрдә булачак съездда бу мәсьәләләр дә күтәреләчәк. Анда 500гә якын делегат катнашачак.

**:: Бүген авыл җирлекләре башлыкларының уртача хезмәт хакы күпме?**

– Муниципаль берәмлекләрдә хезмәт хаклары шул: җитәкчеләрнеке – 23–25 мең сум, өстәмә түләүләр, премияләр белән 45–50 мең сум чыга. Башкарма комитет рәисләренең, хисапчыларның хезмәт хаклары – 18–22 мең сум. Кайбер районнардагы башкарма комитетларда белгечләргә кытлык 10–20 процентны тәшкил итә.

**:: Кайвакыт, авыл җирлеге башлыкларының күп булуы үз-үзен аклыймы икән, дигән сүзләрне дә ишетергә туры килә. Сезнең моңа карата фикерегез нинди?**

– Аларның һәркайсының үз урыны бар. Республикада барлыгы 3100 авыл, 872 җирлек. Уртача алганда, һәркайсына 4әр авыл туры килә. Авылда яшәгән кешенең көндәлек мәшәкатьләре бик күп. Аларны хәл итүдә авыл башлыкларының көче күп керә. Шуңа күрә алар бүген – халыкның төп таянычы. Колхоз-совхозлар вакытында авыл халкы рәис янына бара торган иде. 1990 нчы еллардан соң бу вәкаләтләр авыл советларына күчте. Ә ул елларда аларның мөһердән башка бер нәрсәләре дә юк иде. 131 нче закон нигезендә, һәр вәкаләт финанс белән тәэмин ителгән булырга тиеш. Кызганыч, бурычлар йөкләнә, тик кайберләрен тормышка ашырыр өчен җитәрлек финансланмый. Шуңа күрә менә шушы бушлыкны тутырыр өчен, республикада төрле грантлар, субсидияләр бирелә. Мәсәлән, ел саен 170 авыл советы 1,5 млн сумлык грант ота. Шулай ук үзара салым да күп мөмкинлекләр бирде.

**:: Әлеге теманы дәвам итсәк, башлангыч елларында халык үзара салым программасына шикләнеп карады. Хәзер эш нәтиҗәсе күз алдында булгач, 1000–2000 сум акча җыючы авыллар да бар. Шул ук вакытта 300–400 сум җыярга каршы килүчеләр дә юк түгел. Монда сәбәп нидә?**

– Аңлату эшләре җитеп бетмәүдә. Халыкны җыеп, барысын да уртага салып сөйләшергә кирәк. Хәзер андыйлар саны аз инде. Ничек кенә булмасын, программага ышаныч елдан-ел арта. Узган ел халыктан 256 млн сум акча җыелды. Һәм ул акча 1 млрд 200 млн сум булып кайтты. Әлеге вакытта да киләсе ел өчен җыеннар бара. Ләкин мин халыктан зур суммада акча җыю яклы түгелмен. Элек бит бер авылдагы эшләрне гомуми суммадан башкаралар иде. Хәзер һәр авыл халкы үзе өчен үзе җыя.

**:: Сез үзегез шәхсән авыл башлыклары белән ни дәрәҗәдә еш очрашасыз?**

– Елына ике тапкыр барлык авыл советы башлыкларын зональ киңәшмәгә җыябыз. Монда нәтиҗәләр ясала, планнар билгеләнә. Аннан соң кайсы гына районга барсам да, җирле үзидарә башлыкларын җыеп сөйләшәбез. Болардан тыш, онлайн да, телефон аша да даими рәвештә элемтәдә торабыз.

Зөһрә САДЫЙКОВА

**Муниципаль берәмлекләр советы – саннарда**

➤Муниципаль берәмлекләр башлыклары вазыйфасын 896 кеше били.

➤42 муниципаль район башлыклары район белән җитәкчелек итүне шәһәр (29) яки авыл (13) җирлеге белән җитәкчелек итүне бергә алып бара.

➤Авыл советы башлыкларының уртача яше – 45 яшь. 35 яшькә кадәр – 8, 35–50 яшькә кадәр – 35, 50 яшьтән өлкәнрәкләр 57 проценты тәшкил итә.

➤Муниципаль берәмлекләр башлыкларының 80,8 процентының – югары, 17 процентының – урта махсус, 2,3 процентының урта белеме бар.

# ҖИРСҮ

## Чечня көндәлеге

< Дәвамы. Башы 8, 15 декабрь саннарында

Чечняда медицина мәсьәләсе мине барысыннан да ныграк куркыткан тармак булгандыр. Чөнки мин болай да медицинадан корт чаккандай куркам. Яшереп-нитеп торасы түгелдер, Казандагы балалар белән бәйле медицина чараларын мин түләүле хезмәтләргә кайтарып калдырып бетергән идем. Сәбәбе – бушлай медицинага җитәрлек нерв күзәнәкләре булмау. Балалар сырхауханәсендәге күргән «мәрхәмәтлелек» ген дәрәҗәсендә сеңеп калырлыктыр ул, билләһи. Ишектән керә-керешкә эткәләшү-төрткәләшү, регистратурадан башлап табиб кабинетына кадәр үзеңне кемгәдер нидер тиеш дәрәҗәсенә төшеп, каударлана-каударлана каушау (ә сине аның саен куалыйлар, син бөтен дөньяга тиеш, чөнки мондагылар түгел, ә син бала күтәреп килгәнсең), ишек төбендәге электрон чират алып килүчеләр белән талашырга әзерлек...

Берсендә авыру балалы әнине үземнән алда уздырган өчен талап үтерәләрме әллә дип торам! Кем кушкан аңа андый бала табарга, диде бер бик мәрхәмәтле әнкә. «Бик игелек иясе икәнсең, утыр дәлше, мин ике кеше үткәрергә тиеш түгел, хәзер синең урынга мин керәм!» – дип бугазга басты миннән артта торганы. Әле тагын ике яшьтә манту ясатырга оныткан өчен медсестраның уттан алып утка бастыруын ишетергә кирәк. Җинаять кылганмынмыни! Коелып иңәсең, ярты картаеп чыгасың. Бу – чынбарлык. Кая инде анда нинди-дер гозер белән бару: медосмотрны түләүле клиникада үтәсең, прививканы түләүледә ясатасың. Мәйтәм, яңа күлмәк алмыйча торсам торам, әмма кешечә кабул итә торган җиргә барам. Үзем тыныч, бала тыныч, нервылар – тулы составта.

Грозныйга килеп урнашкач, мәктәп-бакча өчен карталарны яши торган җир буенча балалар сырхауханәсенә теркәдек дә онытык бит инде. Теге анализ кирәк, бусы – түләүле медицина үзәгенә барабыз да тапшырабыз. Бер бардык, ике бардык, аннан бер кәгазьне участок педиатрында раслатырга кирәк булды. Киттем инде. Бушлай медицинаның бөтен матурлыкларын онытканысыңдыр, мәйтәм, бар, хушланып кайт әле, туган...

Мондагы рәсми тәртип бездәгечә дисәң дә була: иртән йә шалтыратып языласың, йә колл-үзәк аша. Әмма бүген, хәзер кирәк икән, язылмыйча килгәнне дә педиатр чираттан тыш кабул итә (мин нәрсә, тиешле нормадан күбрәк эшләргә тиешме әллә, язылмагансыз икән, килмәгез, сез генә әллә, минем эш сәгате... һәм башка сүзләрне әйтмичә дә була икән), аннан тыш та бер буш дежур педиатр кизү тора. Мисалга, бүген кирәк икән, бүген үк балаңны күрсәтә аласың.

Мин үзебезнең район педиатрына туры килдем. Язылмыйча. Беренче килүдә үк. Юк-юк, сез мине язгыз да, мин иртәгә сез әйткән вакытка килермен, дип әйтеп торып! «Шуның өчен ике тапкыр килеп йөрергәме? Бераз көтеп утырыгыз да кабул итәр педиатр», – диде регистратурадагы кыз. Елмаеп. Итагатьле итеп. Педиатр исә баланың анализларын карауга, аптырап: «Нишләп әлеге анализларны бездә бирмәдегез, ник акча әрәм итеп йөрисез?» – диде. Монда педиатр һәр бала белән үзе тыгыз элемтәдә икән: бу прививка кирәк, манту вакыты җиткән, дип шалтыратып тора.

Ә коридорда ким дигәндә 3–4 балалы әниләр. Аларның берсе-бер ызгышмый, бер-берсен таламый, теге чират, бу чират, соңгы сүзләрен әйтә-әйтә, бер-берләренең канын эчми. Еллык медосмотр үткәндә УЗИга чират торабыз, Әминәнең түземе төкәнде: чәй эчәсе килә. Алда ике кеше калды, китеп тә булмый... Безне этеп-төртеп диярлек кертеп җибәрделәр – аларныкы шыңшымый бит әле, янәсе. Без чыгуга, бар, җимеш, бар, чәй эч, дип ашханәгә кул болгап озатып калдылар.

Медосмотрны бер көндә бернинди нервы бетерүләрсез бушка үттек. Анысын да регистратурада көйләп бетереп бирәләр: әниләр бишәр кат, бишәр көн рәттән сырхауханә ишек төбен таптамасын өчен эшләнә ул. Әбәдкә кадәр лаборатор анализлар, УЗИ үтәсең, аннан соң балаңны ашатасың, үзең тамак ялгыйсың, әбәд соңы – белгечләр. Өчләр тирәсендә педиатрга кереп, картаңны тапшырып, тиешле күрсәтмәләрне алып, өеңә кайтып китәсең. Бер җирдә дә сине куаламыйлар – ике бала белән килгән әниләр мине ничек кенә аңлар!

Участок педиатрының шәхси телефонына шалтыратып, киңәш сорау кебек нәрсәләр дә фантастика жанрыннан түгел – тормыштан. Кешелеклелек-кечелеклелекне кушсаң, шундый матур яшәү форматы килеп чыга!..

Табибларга акча төртмиләрмени, ие менә йөгереп төшәләрдер, дигәннәр өчен. Бирәләрдер, кулларыннан тотмадым. Әмма мин аның башкасына басым ясыйсым килә: кешечә мөнәсәбәт бар, кешене кешедән аерып карау юк. Медицина оешмаларында да шулай – теш арасыннан ысылдап җавап бирү, «анысы – сезнең проблема» дип борып җибәрү юк – дәррәү ярдәмгә ашыгалар. Килгән кешеләргә генә түгел, үзара шулай.

Сүзләремне мондагы җирле хастаханәдә табиб булып эшләүче, аңа кадәр Мәскәүдә эшләп килгән иптәш кызым да җөпли: «Бер-береңне сөйләү, сату, әләк йөртү юк – шул яктан эшләү рәхәт монда. Диндәге сабырлык дигәннәре шулдыр – коридорда да пациентларның ямьсезләшеп талашканнарын ишеткәнем юк. Монда эшләгән 5 елымда бер тапкыр гына ике айлык бала коклюш белән чирләп, мин билгеләгән дәвалауга риза булмыйча, баланы Мәскәү хастаханәсенә алып киткән очрак булды. Әмма әнисе ызгышмады».

Ашыкмау, каударланмау, соңга калам, дип өзгәләнмәү, нәрсә өчендер ызгышырга-дөреслек эзләргә керешмәүне чеченнар бик гади аңлата: барыбер Аллаһы язганча була, керә алмасаң, соңга калсаң да, куркыныч юк, димәк, Аллаһы Тәгалә шулай язган. Кешелеклелегеңне генә өйдә калдырма да мөселман икәнлегеңне генә онытма...

Гөлнара ҖӘЛИЛОВА

Ахыры бар >

# КОТЛЫЙБЫЗ!

«ТГК-16» акционерлык җәмгыятенең «Казан Җылылык-электр үзәге – 3» филиалы баш инженеры урынбасары (эксплуатация буенча) **Васильцов** Александр Николаевичка, «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыятенең «Түбән Кама электр челтәрләре» филиалы ярдәмче станцияләр хезмәтенең Пучы ярдәмче станцияләр төркеме электрбүлгеч җайланмалар җиһазларын төзекләндерү буенча электрослесаре **Гыйздәтуллин** Айрат Фәнис улына, «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыятенең «Бөгелмә электр челтәрләре» филиалы Чирмешән электр челтәрләре районы башлыгы **Кәримов** Рамил Әхәт улына, «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенең «Чаллы җылылык-электр үзәге» филиалы пар казаннары цехының пар казаннары һәм тузансыман матдәләр җитештерү цехы җиһазларын төзекләндерү буенча слесаре **Мөхетдинов** Радик Җәмил улына, «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыятенең «Буа электр челтәрләре» филиалы Югары Ослан электр челтәрләре районы башлыгы **Алифанов** Вячеслав Александровичка, «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыятенең «Чистай электр челтәрләре» филиалы югары вольтлы линияләр хезмәте Чистай электр челтәрләре районы участогының электр тапшыру һава линияләрен төзекләндерү буенча электромонтеры **Әхмәтвәлиев** Госман Мәүлемҗан улына, «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыятенең «Идел буе электр челтәрләре» филиалы югары вольтлы линияләр хезмәте башлыгы **Әхмәтҗанов** Хәмзә Газизулла улына, «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыятенең «Түбән Кама электр челтәрләре» филиалы релесаклагыч, автоматика һәм үлчәүләр хезмәте башлыгы урынбасары **Белов** Олег Борисовичка, «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыятенең «Казан электр челтәрләре» филиалы Көнбатыш электр челтәрләре районы электрбүлгеч челтәрләрне эксплуатацияләү буенча электромонтеры **Галимов** Фәнис Харис улына, «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыятенең «Бөгелмә электр челтәрләре» филиалы Баулы электр челтәрләре районы участок мастеры **Зиннәтуллин** Айдар Мирхатим улына, «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыятенең «Әлмәт электр челтәрләре» филиалы мәгълүмат технологияләре хезмәте башлыгы **Миңневәлиев** Равил Мансур улына, «Түбән Кама нефтехим» гавами акционерлык җәмгыяте II сәнәгать зонасы заводлары электр җиһазларын эксплуатацияләү һәм төзекләндерү идарәсе этилен, стирол һәм полиэфир сумалалар җитештерү заводлары электр җиһазларын эксплуатацияләү һәм төзекләндерү цехының электр җиһазларын төзекләндерү һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча электромонтеры **Мулләхмәтов** Ринат Нургаян улына, «Төзелеш һәм архитектура буенча Татарстан Республикасының дәүләт экспертизасы һәм бәяләр кую идарәсе» дәүләт автоном учреждениесе инженерлык тәэминаты бүлеге башлыгы **Боярин** Игорь Юрьевичка, «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенең эксплуатация хезмәте башлыгы урынбасары **Нотфуллин** Рәис Галимулла улына, «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенең персонал белән эшләү идарәсе башлыгы **Ячина** Елена Владимировнага **«Татарстан Республикасының атказанган энергетигы»** дигән мактаулы исем бирелде.

# МОҢЫБЫЗ САГЫНДА

## БАЯНЧЫ РАМИЛ КУРАМШИН ИҖАТЫ ҺӘМ АНЫҢ ИСЕМЕНДӘГЕ РЕСПУБЛИКА БӘЙГЕСЕ ТУРЫНДА

Татарстанның халык артисты Рамил Курамшин – гомере буе халкыбызга милли моңнарыбызны җиткергән һәм бөек җырчы Илһам Шакировка егерме елга якын уйнаган талантлы аккомпаниатор. Заманында Мөхтәр Әхмәдиев, Фәйзи Садыйковларның моңнарын саклап һәм яңа аһәңнәр белән баетып, профессиональ югарылыкта башкарган талантлы баянчы булу белән беррәттән бик күп җырларга һәм көйләргә яңа сулыш өрүче дә. Аның «Баян өчен пьеса», «Шаяру», «Концерт пьесасы», «Төймә», «Карабай», «Җыен көе», «Чәчтем бодай», «Бишле бию», «Сирәкмирәк», «Җәйге авыл урамында», «Ташлар аттым Болакка», «Күңелле гармунчы», «Эрбет», «Баек», «Авыл яшьләре», «Бию», «Киндер сукканда», «Әпипә», «Гармун-патефон», «Җаек күгәрчене», «Скерцо» (3 кисәктән торган) һ.б. әсәрләре баянчылар арасында зур популярлык казанды.

1975 елда Рамил абый Курамшин татар музыкасы тарихында беренче булып «Баян һәм оркестр өчен концертино» дигән күләмле әсәр иҗат итә һәм баян партиясен үзе башкарып, аны радио һәм телевидение фондына яздыра. Сиксәненче еллар уртасында бу әсәр СССР телевидениесе аша да халыкка җиткерелә. Бөтенсоюз телевидениесендә татар баянчысының чыгышы – бу да беренче мәртәбә була.

1980 елдан Казан телевидениесендә Рамил Курамшин шулай ук беренчеләрдән булып сольный концерты белән чыгыш ясый.

Аның иҗади эшчәнлеге хакында сәхнәдәше, баянчы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Хәйдәр Сафин болай дип хәтер яңарта: «Рамил Курамшин – гаҗәеп киңкырлы талант. Илһам абый Шакировка гомере буе уйнап йөргәч, аңа сокланып, үзенең дә җырлыйсы килә башлый. Әлбәттә, минем аның сәхнә артында җырлаштырганын ишеткәнем бар иде. Шулай бер кунакханәдә җырлаганын музыкантлар ишеткәч, автобуста барганда: «Рамил абый, син бүген кич буе моңландың, мөгаен, бүген концертта да җырларсың», – дип шаярттылар. Илһам абый борылды да: «Ә нигә җырламаска, ул бүген җырлый!» – диде. Рамил Курамшинны сәхнәгә чыгарганда, ул: «Рамил Курамшинны беләсез инде, ул – бик оста баянчы, җырчы да, әмма әлегә сәхнәдә җырлаганы юк, ул базда, мунчада, юрган астында качып кына җырлап йөри иде. Ә инде Ходайдан яшермәгәнне, бәндәдән яшереп булмаган кебек, бүген сезнең каршыгызда җырлар!» – ди, аннары рояль артына барып утырып уйнап җибәрә иде. Шаккаткыч күренеш иде бу. Бөек музыкант белән бөек җырчының шулай бер-берсен тулыландырып сәхнәдә эшләүләренә мин шакката идем. Рамил әкә гомере буе формада булды, үзе язды, үзе уйнады. Күләмле концерт әсәре язу теләге хыялында тугач та, оркестр белән уйныйсы килә башлады. Ул язган әсәрләрне тыңлаган сәнгать киңәшмәсендә Рөстәм Яхин да булып, аңа югары бәя бирә, аны иҗатка рухландыра иде.

Тора-бара Рамилебезнең иҗат үрнәкләрен Владимир Федотов, Виктор Гридин, «Урал триосы» музыкантлары, Рәҗәп Шәйхетдинов, Айдар Гайнуллин (Мәскәү), Айнур Фатыйхов (Уфа), Айдар Вәлиев һ.б. яратып башкара.

Аның әсәрләрен яшь музыкантлар, студентлар үзләренең репертуарларына кертеп, сәхнәләрдә яңгыраталар. Бу юнәлештә Арчада инде быел сигезенче тапкыр узучы Рамил Курамшин исемендәге Республика баянчылар һәм гармунчылар бәйгесе дә үз ролен бик төгәл үти. Аның беренчесе, виртуоз музыкантның 60 яшьлегенә туры китереп, Арча педагогия көллиятенең музыка бүлегендә оештырылган иде. Көллияттә укытучы булып эшләүче, үзе дә баянчы Филорит Гасыймов һәм сәхнәдәше Хәйдәр Сафин – бәйгенең башында торучылар. Бәйгедә мәктәп укучылары да, көллияттә белем алучылар да катнаша, аларга Рамил Курамшинның бер әсәрен һәм татар халык көен башкару мәслихәт. Бәйге «баян», «гармун (тальян гармун)», «аккомпаниатор» номинацияләрендә үтә.

Элеккеге елларда Рамил Курамшин җитәкләгән жюрида консерватория укытучысы Таһир Сөләйманов, шулай ук танылган баянчы, мөгаллим Харис Нигъмәтҗанов та бар иде. Кызганыч, хәзер алар бу чараларда катнаша алмыйлар, Харис ага быел арабыздан китте, Рамил абый Курамшин сәламәтлегенә бәйле рәвештә Арчага кайта алмады. Рамил Курамшинның инструменталь әсәрләрен сәхнәдә, чит илләрдә яңгыраткан музыкант, халыкара конкурслар лауреаты Айдар Вәлиев жюри рәисе буларак талантлы балаларны барлауда катнашты, соңыннан үзе дә чыгыш ясап, бәйгедә катнашучыларга мастер-класс күрсәтте. «Рамил абый безнең өчен маяк булып тора, профессиональ уйнау осталыгы иң беренче Рамил абыйдан башлана, ул – яшьләргә үзе бер мәктәп», – ди Айдар.

«Пандемиягә бәйле рәвештә бу эш сүлпәнрәк барса да, без аның яхшы узачагына өметебезне өзмәдек. Быел Казан музыка училищесы студентлары да катнашты. Элек бәйге Президент каршындагы мәдәниятне үстерү фонды ярдәме белән үткәрелә иде, без Нурия Һашимовага бик рәхмәтле. Бүген ул Татарстан Мәдәният министрлыгы карамагына күчте, Арча мәдәният йортында узды. Бәйге киләчәктә дә дәвамлы булсын иде», – ди Хәйдәр абый Сафин.

Әле шушы көннәрдә генә булып узган бәйгедә Ильяс Әүхәдиев исемендәге Казан музыка көллиятенең икенче курс студенты Айбулат Харисов гран-при иясе булды. Яшьләребез өметле, киләчәгебез якты, нурлы, моңлы.

Алсу ХӘКИМОВА,
Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре

# КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты, ире
**ЛАРИОНОВ Евгений Леонидович**
вафат булу сәбәпле, VIII чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы депутаты Ларионова Татьяна Петровнаның авыр кайгысын уртаклаша.

Спорт

# Футбол туктады, уен – юк

**Венгриянең «Ференцварош» командасына яңа баш тренер билгеләделәр. Бу хәбәрнең Татарстан спортына ни катнашы бар диярсез? Бөтенләй үк юк түгел. Чөнки бу вазыйфаны Россия җыелма командасының элеккеге баш тренеры Станислав Черчесов башкарачак. Аны исә узган атнада армый-талмый «Рубин»га кодаладылар.**

Казан клубының генераль директоры Рөстәм Сайманов бу хәбәрләрне кире какты, «саташу» дип атады. Әмма Черчесов мадьяр клубы белән килешү имзалаганчы, аның «Рубин»га киләсен һәм Леонид Слуцкийны алмаштырасын тукып тордылар. Атна-ун көн элек футбол дөньясын Слуцкийның әңгәмәсе шаулатып алган иде. Ике вакыйга арасында бернинди дә бәйлелек юк. Әйе, «Рубин»ның баш тренеры матур һәм үтемле итеп сөйли. Ләкин шәхесенә карата игътибар аның бу таланты өчен түгел, ә Казан командасының начар уены аркасында килеп чыкты. Премьер-лигадагы тәнәфес алдыннан безнекеләр рәттән өч җиңелүгә дучар булды. Якташларыбыз турнир таблицасында нибары 10 нчы урында.

Очко гына түгел, уенда ниндидер өмет тә күренми. Аңлашыла инде: җәй көне «Рубин» берничә уенчысын башка командаларга җибәрде. Араларыннан икесе – «Селтик»ка киткән Карл Старфельт һәм «Динамо»га күчкән Денис Макаров Слуцкий командасында аеруча мөһим уенчылар саналды. Алар урынына килгән футболчыларны да шәп дип әйттеләр. Тик араларыннан бары Дания егете Андерс Дрейр гына үз бәясен аклый булып чыкты. Калганнары алыштыргысыз егетләр түгел әлегә. Былтыр лидер булган һәм үзен атаклы «Барселона»да уйнарга лаек дип санаган һөҗүмче Джордже Деспотович имгәнеп, ярымсакчы Хвича Кварацхелия Европага китү хыялыннан арына алмагач, «Рубин» турнир таблицасының аскы өлешенә төшәргә мәҗбүр булды.

Димәк, кышын командада үзгәрешләр көтәсе. Имеш-мимешләргә ышансаң, Казанга хәтта Артем Дзюба да килергә мөмкин икән. «Зенит»та бу хәбәрне кире кактылар. Әмма кем белә? Кайчандыр «Рубин»да туп типкән Мөхәммәд Оздоев белән дә шул ук хәл. Соңгы көннәрдә «Спартак» уенчысы Александр Ломовицкийны Казанга кодалыйлар. Килүче табыла икән, китүчесе дә булачак. Һәрвакыттагыча Кварацхелияне телгә алалар. Дөрес булса, аны берьюлы өч инглиз клубы үзенә чакыра икән. Казан ягы инде бәяне дә әйтеп куйган: 13 миллион фунт стерлинг – шуннан да очсызракка эләкмәячәк икән грузин егете. Безнең акчага күчерү мөмкинлеге булмаганнарга ярдәм: 1 миллиард 300 миллион сум тирәсе була бу.

rubin-kazan.ru

Белми калмагыз!

## «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»ГА ЯЗЫЛУЧЫГА – МИНИ-ТРАКТОР

**БҮЛӘКНЕ АЛУ ШАРТЛАРЫ**

1 2022 елның беренче яртыеллыгына 6 айга «Ватаным Татарстан» газетасына язылырга.

2 Язылу квитанциясен безгә җибәрергә: «Ватсап» (89179270040) яки почта аша (420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт, «ВТ» газетасы редакциясе), яки электрон адреска (info@vatantat.ru).

БЕЛЕШМӘЛӘР ӨЧЕН ТЕЛЕФОН: 8-917-927-00-40

Җиңүче жирәбә юлы белән ачыкланачак. Квитанцияләр 2022 елның 16 гыйнварына кадәр кабул ителә, жирәбә 20 гыйнвар көнне үткәреләчәк.

*Акциянең оештыручы: «Ватаным Татарстан» газетасы ДБУ, акцияне уздыру вакыты 2021 елның 1 ноябреннән 2022 елның 15 февраленә кадәр. Тулырак мәгълүмат vatantat.ru сайтында.*

УРАЛЕЦ ТОРГОВЫЙ ДОМ МЫ ПРОДАЁМ НАДЁЖНОСТЬ

**АКЦИЯНЕҢ ИГАНӘЧЕСЕ – «УРАЛЕЦ» СӘҮДӘ ЙОРТЫ**

- ✓ мини-тракторлар;
- ✓ барлык төр тракторлар өчен запас частьлар;
- ✓ җир эшкәртү, чәчү, җыйнау өчен асылмалы җиһазлар.

Казан ш., Мамадыш тракты, 35А; Чаллы ш., Казан проспекты, 252/1; Әлмәт ш., Советская урамы, 42А.

**ТЕЛЕФОННАР: 8-927-465-12-94, 8-987-931-55-50**

## ГАЗЕТАГА ЯЗЫЛУ ЫСУЛЛАРЫ




1 **ПОЧТА БҮЛЕКЧӘЛӘРЕНДӘ**

2 **ОНЛАЙН:** **vatantat.ru сайтындагы сылтама аша газетага язылу бик уңайлы һәм тиз. Программа үзе адымлап алып бара.**

**Әлеге QR-код ярдәмендә телефон аша газетага язылырга һәм акча түләргә мөмкин.**

*2022 елның беренче яртыеллыгы өчен 6 айга язылу бәяләре*

| | | | |
|---|---|---|---|
| П2435 атнага бер, җомга килә | 465 сум | П2409 Сишәмбе, чәршәмбе, җомга, шимбә килә | 1000,92 сум |

Реклама 16+

# ҖӘМИЛӘ КЕРИМОВА: «КЕШЕ ПЕШЕРГӘННЕ АШАУ – ЯЛКАУЛЫК ТҮГЕЛ»

Соклану

**Җәмилә Керимова пешергән ризыкларны мактап туя алмыйлар. Читтән эшләгәнен карап торсаң, аның кулы кулга йокмый. Беркая кабаланмый, ашыкмый, шул ук вакытта тиз арада өстәл тутырып ризык әзерләп куя. Тәҗрибәсе зур Җәмиләнең. Эш урынында пешерү генә җитмәгән, буш вакытында да тик утырмый: заказга азәрбайҗан, татар, грузин, төрек ризыкларын әзерләп бирә. «Эшсез торсам, күңелгә нидер җитми кебек. Мин ял итәргә өйрәнмәгән», – ди Җәмилә.**

Казанга килгәненә дә 34 ел була икән инде. Булачак ире белән Бакуда бер сыйныфта укыган ул. Мәктәпне бетергәч, егет, белем алырга дип, Казанга юл тота. Укый да, шул ук вакытта заводта да эшли. Ә бер елдан кайта да үзе белән Җәмиләне алып китә. Туйны Казанда үткәрәләр.

– Иремнең дуслары безгә бер дигән бәйрәм ясады, – дип искә ала Җәмилә. – Өйләнешкәч, эш урыныннан тулай торакта бүлмә бирделәр. Мин дә заводка урнаштым. Дөрес, озак эшләргә туры килмәде. Башта кызыбыз Амалияне алып кайттым. Бер ел да үтмәде, улыбыз Рамин туды. Өченче балам Ләйланы 41 яшемдә таптым. Хәзер аңа 14 тулды инде. Әле ярый куркып калмаганмын, дим. Өйдә кызым булгач, шулкадәр рәхәт. Олы кызым әзәри егетенә кияүгә чыгып, Мари Илендә яшиләр. Игезәк малайлар үстерәләр. Улым әлегә ялгыз.

Җәмиләнең дә, иренең дә туганнары күп Казанда. Татарлар белән туганлашып беткәннәр. Ике милләт бик тату яшибез, ди Җәмилә.

– Олы абыем үлгәнгә 18 ел инде. Шуңа да карамастан, киленебез бик якын итә. Кунакларга йөрешәбез, йә алар безгә килә, йә без барабыз. Татар кызларының иң уңганнары эләкте безгә. Миңа милли ризыкларны да алар өйрәтте. Мин өчпочмак та пешерәм, мантый да, бәлеш тә, өлеш тә, гөбәдия дә ясыйм. Аш токмачы да кисәм. Нинди ризык ашап карыйсыбыз килә – шуны пешерә алам, – ди ул.

Моннан ел ярым элек Җәмилә заказга да ризыклар пешерә башлаган.

– Үземә пешергәнне интернетка куйган идек, заказлар бирә башладылар. Азәрбайҗан ризыкларын яратып ашыйлар. Гөбәдия, бәлешне дә еш сорыйлар. Пешергәндә намус турында истән чыгармыйм. Кеше 1 кило ризык сораса, артыграк итеп әзерлим. Минем өчен сан түгел, сыйфат кирәк, – ди ул. – Кайбер бәйрәмнәргә өстәл дә корып бирәм. Башта заказ бирүче белән бергәләп меню төзибез. Әзерләп бетергәч, ризыкларны килеп алалар. Кайбер клиентлар белән хәтта очрашкан да юк. Ике арада такси йөри. Кешедән сорап эшләтәләр икән, бу әле ялкаулык дигән сүз түгел. Хәзер кеше бик арый. Эштән соң бәйрәм ясарлык рәте калмый. Болай эшләгәндә, вакыт та янга кала, мәҗлескә дә арыган килеш бармыйсың.

Җәмиләдән: «Ризыкларыгыз гел уңамы?» – дип сорыйм. Ә ул бер дә икеләнмичә, әйе, ди. Үзенә нык ышанган ул. Ышанмаса, туган яктан читтә өч бала үстереп, күпме туганны бер учка җыеп тора алыр идеме? Әнә бит ире Сарраф та күзләренә генә карап тора. Аларга карагач, яратуның нинди тылсымлы икәнен аңлыйсың. Гаиләдә аңлаучың булганда, сине үсендереп торганда гына ризык та тәмле, өй дә ямьле буладыр ул!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

**ҖӘМИЛӘДӘН БОЗБАШ РЕЦЕПТЫ**

Әлеге ризык өчен 1 килограмм сөякле ит, 4 бәрәңге, 1 суган, 100 г нут борчагы, 5 данә борыч, 2 аш кашыгы томат пастасы, 1 аш кашыгы тоз кирәк була. Иң элек нут борчагын 3 сәгатькә суга салып торабыз. Аннары кәстрүлгә су, ит салып шулпа куябыз. Ул кайнап чыккач, нут салабыз. Алар пешкән вакытта суганны вак итеп турарга һәм алтынсу төскә кергәнче кыздырырга кирәк була. Шуңа 2 кашык томат пастасын кушабыз. Алар өстенә чистартылган бәрәңгене эре итеп турап салып, аз гына кыздырабыз. Шулар өстенә шулпаны салабыз. Итне кисәкләргә бүләргә кирәк. Бәрәңге пешкәнче кайнатабыз. Бозбашны табынга яшел тәмләткечләр белән чыгарабыз.

# ГРАЖДАННАР СУГЫШЫ

Язучы фикере

Марат КӘБИРОВ

pixabay.com

Бер танышым сөйли... Полициядә эшли ул... Ну аларда бер өлкән лейтенант инде, старлей гади сөйләм телендә... Ну яхшы егет, ну бераз уңга да йөри. Калган вакытын сулда уздыра. Нәтиҗәле хезмәт көненнән соң якындагы сыраханәгә керә бу, кирәк бит инде намустагы кирләрне юып төшерергә. Вәт шунда бер матур ханым белән таныша, ә тегесе үзенә кунакка чакыра: ну, әйдә, сөйләшеп утырабыз, иртәнге аш ашап китәрсең. Хатын-кыз сүзе закон бит инде, үз хатының булмаса – бигрәк тә.

Төн ничек узганы турында тарих берни дәшми. Ә таң белән, ну сәгать җиделәр тирәсендә теге ханым старлейны уята һәм тотлыга-тотлыга нәрсәдер аңлатырга маташа. Ишектәге кыңгырау тавышын ишетүгә старлей үзе дә аңлый, әлеге ханымның ире бар икән һәм ул бик еракта түгел икән, ишек артында гына икән...

Мондый очракта чын ир-егет нәрсә эшли инде? Чалбар, күлмәк, ботинка, куртка... Болар барысы да тиз генә, караваттан балконга кадәр арада киелә һәм... Ну сулга йөреп өйрәнгән кеше өчен гадәти күнекмә... Ә урамда – кыш, балкон астында – кар... Ә кар – муеннан... Космостан сикерсәң дә, исән калырлык...

Ләкин тормыш бөтен тулылыгында ага...

Кышкы матур иртә. Талгын гына кар ява. Әби кеше этен урамга алып чыга. Ләкин ерак китә алмый, шушы тирәдә яшәүче бер алкаш ир моңа акча сорап бәйләнә. Алкашы да андый-мондый гына нәрсә түгел, ә шкаф зурлыгы. Сукса – ега, ауса – торгызып булмый торган. Һәм әби... Ну ул нәрсә эшли ала инде бу очракта, ул бар хутына сөрәнли:

– Милитсия! Милитсия, ананңы! Коткарыгыз!

Һәм шунда кинәт... өченче каттан кокардалар, погондагы йолдызлар ялтырап кала һәм бер полицейский килеп төшә. Төшкән уңайга хәлне аңлап ала да теге хулиганны бәреп ега бу һәм карчыкка эндәшә:

– Әби, озак көтмәдегезме?!

Әби ни әйтергә белми катып кала. Әлбәттә, аның китап укыганы да, кино караганы да бар. Әмма безнең полицейскийлар шул дәрәҗәдә эшли аладыр дип уйлаганы гына юк. Күз алдыңа гына китер, ярдәм сорап бер кычкыру белән һавадан полицейский килеп төшсен әле! Горурлык ич бу!

Ләкин тормыш тулы кан белән ага...

Бу вакытта теге ханымның ире, нәрсәдәндер шикләнеп, балконга ташлана һәм полицейскийның бер әзмәверне җиргә сузып салганын күреп кала. Балконнан сикерүчене полицейский, карак дип уйлап, җиргә яткызды, дигән нәтиҗәгә килә ул һәм баскычка ташлана. Үч алу теләге көч тә, дәрт тә, җитезлек тә өсти. Моңа кадәр дә шикләнә иде ич, ә монда – барысы да әзер, теге азгынның иманын киярргә генә кирәк. Йөгереп килеп, җирдә яткан азгын бәндәнең иң авырткан җиренә тибәргә генә дигәндә таеп егыла һәм нәфрәт белән тулы аягы старлейның башына эләгә.

«Ух, зараза, бу барысын да аңлаган» дигән уйлар белән полицейский караңгылыкка чума. Һәм торырга маташкан җиреннән кабат җиргә сузылып ята.

Ә тормыш... дәвам итә...

Бу арада теге «шкаф» һушына килә. Һәм батырларча торып баскан ирне күреп кала. Үзен сугып егучы кеше шушы икән дип, аңа берне манчый, теге егылгач, бер тибәргәме, әллә ике тапкырмы дип уйланып торганда югарыдан чыелдык тавыш ишетелә. «Шкаф» башын күтәрә. Һәм... ниндидер кара нәрсә төшә... Аның ни икәнен аңлап өлгергәнче теге кара нәрсә аның маңгае белән очраша. «Шкаф»-ир һуштан язып егыла.

Тормышта барысы да гади генә.

Иренең ярсып төшеп китүен күргән хатын, аны туктатып булмасын аңлап, балконга ташлана, ә аста... аста аның ирен кыйнап маташалар... һәм ханым кулына беренче эләккән нәрсәне алып аска томыра... Аны кыйнаучыга... Ну кул астына казан эләгә... Казан теге шкаф зурлыгындагы ирне һуштан яздыра...

Финал. Балконнан түбән карап катып калган хатын. Һәм... Баядан бирле елмаеп басып торган карчык. Хатын-кызлар гына исән калган.

Дөреслек җиңә. Яки нәрсә җиңә, шул – дөреслек.

**Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы**

Газетаны оештыручылар: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430. Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

**Тираж – 7387 данә**
**Гомуми тираж – 17167 данә**

**Газетага сертификат бирелде** Заказ 387

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й. «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

**www.vatantat.ru**

**info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru**

**89179270040**

**Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)**
**П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)**
**П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)**
**П2435 (җомга саны)**

ТЕЛЕФОННАР

**222-09-70** – кабул итү бүлмәсе
**222-09-67** – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
**222-09-73, 222-09-69, 222-09-65** – баш мөхәррир урынбасарлары
**222-09-68** – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
**222-09-67** – дин, сәламәтлек
**222-09-64** – әдәбият, сайт
**222-09-66** – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
**222-09-65** – реклама бүлеге
**222-09-72** – бухгалтерия
**222-09-73** – компьютер үзәге
**221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә**

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
**R** тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
**N** тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт. График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+